ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛЫН-БАЛЫКЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2023 ел, 16 октябрь №136

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының "Болын-Балыкчы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы номерлы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Болын-Балыкчы авыл җирлеге советының 2021 елның 17 августындагы 44 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Болын-Балыкчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1)10 статьяның 5 пунктында «дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар җирләренә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2)10 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Шәһәр төзелеше регламентлары махсус икътисадый зоналар һәм алгарышлы үсеш территорияләре чикләрендә урнашкан урман фонды җирләре, җир өсте сулары, запас җирләре, махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләре, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр, җир кишәрлекләре өчен билгеләнми.».

3)20 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне башкарма комитет җитәкчесе карау өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) җирлекнең генераль планы кагыйдәләренең, муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасының мондый генераль планнарга яисә муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү нәтиҗәсендә барлыкка килгән туры килмәве;

1.1) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда үтәү өчен мәҗбүри керүе, җирдән файдалану һәм җирлектә төзелеш алып бару кагыйдәләрендә кертелгән, аэродром янындагы территорияләрдә урнашкан күчемсез милек объектларыннан файдалануның чикләүләрен бозуларны бетерү турында күрсәтмә,

2) территориаль зоналарның чикләрен үзгәртү, шәһәр төзелеше регламентларын үзгәртү турында тәкъдимнәр керү;

3) территорияләрдән, мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләренең урнашу урыны турында белешмәләрнең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында чагылдырылган, күрсәтелгән зоналар, территорияләр чикләренең урнашу урыны тасвирламасына туры килмәве;

3.1)Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына торак пунктларның чикләре турында белешмәләр керткәндә федераль закон нигезендә үзгәртелгән Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында булганәлеге торак пунктларның чикләренең урнашу урынын тасвирлауга торак пунктларның(шул исәптән торак пунктларның чикләренең (торак

пунктларның) җир кишәрлекләре чикләре кисешкән очракта)чикләре турында белешмәләренең туры килмәве;

4) шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән махсус шартлары булган зоналар, федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге истәлекле урыннар территорияләре чикләрендә тулысынча яки өлешчә урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары белән файдалану чикләүләренең Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында булган әлеге зона территория чикләрендә күчемсез милекне куллану чикләүләренә туры килмәве;

5) территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны билгеләү, үзгәртү, туктату, мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен, федераль әһәмияттәге тарихи җирлек территориясен, региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясен билгеләү, үзгәртү;

6) территориянекомплекслыүстерүтурындакарар кабул итү;

7) Кагыйдәләрдәге территориаль зоналарның чикләре турында белешмәләрБердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына территориаль зоналарның чикләре турында белешмәләр керткәндә федераль закон нигезендә үзгәртелгән Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрындагв әлеге территориаль зоналарның чикләре турында тасвирлауга туры килмәве.”;

4) 31 статьяның 3.2 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Һәйкәл яисә ансамбль территориясендә: капиталь төзелеш объектларын төзү һәм капиталь төзелеш объектларының һәйкәл яисә ансамбль территориясендә булган капиталь төзелеш объектларының күләм-пространство характеристикаларын арттыру; мәдәни мирас объектын яисә аның аерым элементларын саклап калу, мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр яисә табигый мохитен саклау эшләреннән тыш, җир, төзелеш, мелиоратив һәм башка эшләр башкару; Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары булган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләре, мәдәни мирас объектлары территорияләрендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләре тыела”;

5) 31 статьяның 3.2 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«истәлекле урын территориясендә рөхсәт ителә: истәлекле урын территориясендә истәлекле урын территориясе чикләрендә урнашкан һәйкәлләрне һәм ансамбльләрне саклау, аны Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү өчен нигез булган һәм мәҗбүри сакланырга тиешле истәлекле урын үзенчәлекләренең сакланышын тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшләр;юкка чыккан шәһәр төзелеше мохитен торгызу максатларында капиталь төзелеш объектларын төзү; капиталь төзелеш объектларын төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү, аны Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү өчен нигез булган һәм мәҗбүри сакланырга тиешле истәлекле урын үзенчәлекләрен саклап калу шарты белән; Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән күпфатирлы йортларда яисә ачыкланган мәдәни мирас объектлары гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләре; истәлекле урын территориясендә урнашкан һәм мәдәни мирас объектлары булмаган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләре».

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1, 2 пунктчалары 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарның 1 пунктындагы 3 пунктчасы 2024 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Болын-Балыкчы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Болын-Балыкчы авыл җирлегебашлыгы,
Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы рәисе Л.М.Гайнетдинов